# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
# МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘЛЕГЕ

## КАРАР

22 февраль 2017 ел №20/1

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2015 елның 26 декабрендәге 108-ТРЗ номерлы һәм 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнарындагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, РФ Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге - « Җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләрен рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2014 елның 1 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы, «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 2016 елның 13 февралендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Тукай муниципаль районының « Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 07 августындагы 5/1 номерлы муниципаль берәмлек Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен Тукай муниципаль районының 35.8 статьясында тулыландырырга: 1) гражданнарга Иштирәк авыл җирлеге территориясендә милек итеп яисә арендага бирелә торган җир участокларының чикле (минималь һәм максималь) күләмнәрен расларга: - индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен - мәйданы 400 кв.метрдан 2500 кв.метрга кадәр; - шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен: а) торак пункт чикләрендә (утар) - 600 кв.м дан 10 000 кв.м га кадәр мәйданлы; б) торак пункт чикләреннән соң (кыр) - мәйданы 1000 кв.м. дан 20 000 кв.м га кадәр;

- крестьян-фермер хуҗалыгын алып бару өчен;

400 кв.метрдан 1500 кв.метрга кадәр мәйданлы һәм торак

пунктлар чикләрендә; -бакчачылык өчен (вакытлыча корылмалар) - мәйданы 400 кв.метрдан 1500 кв.метрга кадәр; -дача төзелеше өчен - 400 кв.метрдан 1500 кв.метрга кадәр мәйданлы. - мини-маркетлар, киосклар өчен, кибетләр урнаштыру өчен 100 кв.м дан 1500 кв.м га кадәр мәйданлы; -сәүдә үзәге, базар урнаштыру өчен: а) мәйданы торак пункт чикләрендә - 1500 кв.м.дан 5000 кв.м.га кадәр; б) торак пункт чикләреннән тыш - 10 000 кв.м мәйданнан 150 000 кв.м га кадәр; -кафе, икмәк пешерү цехлары урнаштыру өчен - 1000 кв.м дан 15 000 кв.м га кадәр мәйданлы; коммуналь һәм транспорт инфраструктурасы объектларын, көймә станцияләрен, эллингларны, элемтә объектларын, электр белән тәэмин итү объектларын, су чыгару объектларын урнаштыру өчен - 50 кв.метрдан 50 000 кв.метрга кадәр мәйдан;

2) күпбалалы гаиләләргә хосусый милеккә индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен 600 кв.м мәйданлы җир кишәрлекләренең чикле (минималь һәм максималь) күләмнәрен расларга. Әлеге карар, элек төзелгән аренда шартнамәләре буенча милеккә яңадан рәсмиләштерелергә тиешле җир кишәрлекләре күләмнәреннән тыш, яңадан рәсмиләштерелә торган барлык җир кишәрлекләренә кагыла.

Әлеге карарны Иштирәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

2. .Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иштирәк авыл җирлеге Советының авыл хуҗалыгы, җир төзелеше, экология һәм табигый ресурслар мәсьәләләре буенча комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе

Г.С. Гарифуллина